# КАРАР

**2022 елның 21 июне** **№ 2**

**Кукмара муниципаль районы Березняк авыл җирлегенең Березняк авылында «Кукмара муниципаль районы Березняк авыл җирлегенең Березняк авылы торак пунктында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2021 елның 21 ноябрендәге 1 номерлы Березняк авылы гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2022 елның 21 июнендә түбәндәге мәсьәлә буенча узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде:

«Кукмара муниципаль районы Березняк авыл җирлегенең Березняк авылында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2021 елның 21 ноябрендәге 1 номерлы Березняк авылы гражданнар җыены карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертү белән килешәсезме:

- 2 пунктка түбәндәге эчтәлекле яңа абзацларны өстәргә:

- янгын гидрантларын, су алу колонкаларын һәм аларны комплектлау җайланмаларын сатып алу һәм урнаштыру (материал сатып алу, килешү буенча эшләр өчен түләү), проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;

«- Березняк авылы зиратын коймалау, капка урнаштыру, склад түбәсен алыштыру, каты коммуналь калдыкларны җыю өчен урын ясау һәм контейнерлар урнаштыру (материал сатып алу, килешү буенча түләү), проект-смета документлары һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;»

«РИЗА» «КАРШЫ»

Гражданнар җыенының йомгаклау беркетмәсе нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә 277 кеше кертелде, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 141.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен җыенда катнашкан 141 кеше тавыш бирде;

«Юк» позициясе өчен гражданнар җыенында катнашкан 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Березняк авыл җирлеге Березняк авылында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыенының нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. Түбәндәге мәсьәлә буенча карарны: «Кукмара муниципаль районы Березняк авыл җирлегенең Березняк авылында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2021 елның 21

ноябрендәге 1 номерлы Березняк авылы гражданнар җыены карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертү белән килешәсезме:

- 2 пунктка түбәндәге эчтәлекле яңа абзацларны өстәргә:

- янгын гидрантларын, су алу колонкаларын һәм аларны комплектлау җайланмаларын сатып алу һәм урнаштыру (материал сатып алу, килешү буенча эшләр өчен түләү), проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;

«- Березняк авылы зиратын коймалау, капка урнаштыру, склад түбәсен алыштыру, каты коммуналь калдыкларны җыю өчен урын ясау һәм контейнерлар урнаштыру (материал сатып алу, килешү буенча түләү), проект-смета документлары һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;»

«РИЗА» «КАРШЫ»

- кабул ителгән дип танырга.

3. Гражданнар җыенның нәтиҗәләрен мәгълүмат стендларында, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында www.pravo.tatarstan.ru адресы буенча урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Березняк авыл җирлеге
башлыгы Р.Ф. Шәрипов

ОГРН 1021607753276
ИНН 1623001847